**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«22» апреля 2019 с. Тюлячи № 262

**2019нчы елның 13нче маеннан 17 маена кадәр хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек үтүче укучылар белән уку-кыр җыеннарын үткәрү турында**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон таләпләрен, Россия Федерациясе оборона министры һәм мәгариф министрының «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә укытуны оештыру инструкциясен раслау турында» 2010нчы елның 24нче февралендәге 96/134нче номерлы боерыгын һәм Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында 1999нчы елның 31нче декабрендәге 1441нче номерлы карары белән расланган нигезләмәләрне үтәү йөзеннән,

Карар бирәм:

1. Районның урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләренең 10нчы сыйныф укучылары белән уку-кыр җыеннарын 2019нчы елның 13нче маеннан 17нче маена кадәр үткәрү.

2. Уку-кыр җыеннарын үткәрү буенча гомуми җитәкчелекне район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә, уку-кыр җыеннары эшләрен оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе Н.В. Карповага йөкләргә, кече калибрлы винтовкадан ату буенча күнегүләр башкаруны оештыру һәм ату вакытында куркынычсызлык чараларын тәэмин итүне район ОСТО Советы рәисе Р.Р. Нуртдиновка йөкләргә.

3. МКУ “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” (Карпова Н.В.):

- уку-кыр җыеннарына җәлеп ителә торган укучылар составын билгеләү, районның мәгариф учреждениеләренең 10 сыйныф укучыларын иратлар белән тәэмин итү, аларны җыю урыннарына чыгуны оештыру, аларны урнаштыру һәм уку процессын оештыру, хәрби-патриотик тәрбия һәм спорт-массакүләм эш чаралары үткәрү;

- җаваплы затларны уку-кыр җыеннарының вакытлыча штатына билгеләү һәм аларны җыенның программасы һәм үз бурычлары белән таныштыру.

4. Район башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) транспорт чыгымнарына, җыенда катнашучыларны тукландыруга, уку-кыр җыеннарында катнашучыларга бүләкләр алуга, кече калибрлы винтовкаларга сугыш кирәк-яраклары сатып алуга, кимерүчеләргә каршы дератизациягә һәм талпаннар дезинсекциясенә акча бүлеп бирергә.

5. Теләче үзәк район хастаханәсенең Баш табиб вазыйфаларын башкаручы (Кашапов Б.Р.):

- җыеннарда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне оештыру, җыеннар уздыру урынында медицина пункты булдыру, аны медицина персоналы һәм «ашыгыч ярдәм» дежур машинасы белән комплектлау, медикаментлар һәм авыруларны эвакуацияләү чаралары белән тәэмин итү.

6. Тәкъдим итү:

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлек җитәкчесе полиция подполковнигы (Зарипов И.С.) җыеннар үткәрү урынында җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;

- авыл җирлекләре башлыкларына, урта гомуми белем бирү мәктәпләре директорларына укучыларны уку-кыр җыеннары оештыру урынына илтүне һәм аннан соң кире алып кайтуны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин